118

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Җирле үзидарә турында" Татарстан
Республикасы Законына өстәмә хакында

I. "Җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына түбәндәге эчтәлектәге өченче өлешне өстәргә:

"Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатлары статусы турында" Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән халык депутатларының җирле Советы халык депутатының хезмәт хокуклары гарантияләре җирле үзидарәнең сайланучан урындагы затларына да кагыла".

II. Әлеге Законның I бүлегенә караган "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатлары статусы турында" Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән халык депутатларының тиешле Советлары вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен - җирле үзидарәнең тиешле сайланучан коллегиаль органнары, ә алар төзелмәгән очракта гражданнарның тиешле җыеннары гамәлгә ашыра.

Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 8 декабре
N 339